| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**19.03.2020** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 538** |

2020 елга гражданнарның кеременең һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмен раслау турында

«Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннары наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының, күрсәтелгән законга кушымтада бәян ителгән, максималь күләмен билгеләү методикасы белән, Россия Төзелеш Министрлыгының «2020 елның беренче яртыеллыгына Россия Федерациясе буенча торак урынының бер квадрат метр гомуми мәйданының нормативы һәм 2020 елның I кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча бер квадрат метр гомуми торак мәйданының уртача базар бәясе күрсәткечләре турында» 2019 елның 19 декабрендәге 827/пр номерлы боерыгы» на нигезләнеп һәм Россия Федерациясе Торак кодексының 91.3 статьясына таянып, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2020 елга социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар дип тану турында карар кабул итү өчен гражданнар кеременең максималь күләмен билгеләргә:

1.1. гаилә әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләме:

1.1.1. ялгыз яшәүче граждан өчен-1 749 792 сум;

1.1.2. ике кешедән торган гаилә өчен-2 227 008 сум;

1.1.3. өч кешедән торган гаилә өчен-2 863 296 сум;

1.1.4. дүрт кешедән торган гаилә өчен-3 817 728 сум;

1.1.5. биш кешедән торган гаилә өчен – 4 772 160 сум;

1.1.6. алты кешедән торган гаилә өчен-5 726 592 сум;

1.1.7. җиде кешедән торган гаилә өчен – 6 681 024 сум;

1.2. гаилә әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакы чиге:

1.2.1. ялгыз яшәүче граждан өчен-35 065,78 сум;

1.2. ике кешедән торган гаилә өчен – 22 314,59 сум;

1.2.3. өч кешедән торган гаилә өчен – 19 126,79 сум.

2. Гражданнарны социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар дип таныганда, «ЗМР торак сәясәте департаменты» МКУнең муниципаль торак фонды бүлегенә әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктчаларында күрсәтелгән күрсәткечләрдән файдаланырга.

3. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлеге начальнигына әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында һәм Интернет челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru -. бастырып чыгарырга

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкченең беренче урынбасары А. В. Старостин

**2020 елга гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмен билгеләү**

# МЕТОДИКАСЫ

1. **Базар бәясенең исәп-хисап күрсәткече**

**СЖ= НП*РС* РЦ, биредә**

СЖ-базар бәясенең исәп-хисап күрсәткече яки мөлкәт хакының иң чик күрсәткече;

НП – гаиләнең бер әгъзасына торак урыны бирү нормасы;

РС-гаилә әгъзалары саны;

РЦ-РФ төзелеш һәм торак - коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан раслана торган 1 кв. м мәйданның уртача исәп-хисап базар бәясе (2020 елның беренче кварталына – 53 024 сум)

а) ялгыз яшәүче граждан өчен:

СЖ= 53 024 *33= 1 749 792

б) ике кешедән торган гаиләгә:

СЖ=53 024 *42= 2 227 008

в) өч кешедән торган гаиләгә:

СЖ=53 024 *18*3= 2 863 296

г) дүрт кешедән торган гаиләгә:

СЖ=53 024 *18*4= 3 817 728

д) биш кешедән торган гаиләгә:

СЖ=53 024 *18*5= 4 772 160

ж) алты кешедән торган гаиләгә:

СЖ=53 024 *18*6= 5 726 592

з) җиде кешедән торган гаиләгә:

СЖ=53 024 *18*7= 6 681 024

**2. Гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең максималь күләме**

**ПД=0,7*СЖ*ПС/ (1-(1+ПС)$^{-КП}$ ) / (0,25*РС),биредә**

СЖ-социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны бирү нормасы буенча торак урыны алу өчен базар хакының исәпләнгән күрсәткече;

Кредит буенча айлык ПС – процент ставкасы (6,25/12);

КП – кредитның бөтен срогы өчен кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (айлар саны);

РС-гаилә әгъзалары саны;

0,7-кредит суммасы һәм фатир бәясе нисбәте;

0,25 – кредит буенча түләүнең гаиләнең айлык җыелма кереме белән чагыштырмасы;

а) ялгыз яшәүче граждан өчен:

ПД =0,7*1 749 792*0,0052 / (1-(1+0,0052)-$^{250)}$)/ (0,25*1)= 35 065,78

б) ике кешедән торган гаиләгә:

ПД =0,7*2 227 008*0,0052 / (1-(1+0,0052)$^{-250}$ )/ (0,25*2)= 22 314,59

в) өч кешедән һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаиләгә:

ПД =0,7*2 863 296*0,0052 / (1-(1+0,0052)-$^{250}$ )/ (0,25*3)= 19 126,79

г) дүрт кешедән һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаиләгә:

ПД =0,7*3 817 728*0,0052 / (1-(1+0,0052)-$^{250}$ )/ (0,25*4)= 19 126,79

«Зеленодольск муниципаль районы
торак сәясәте департаменты» МКУ җитәкчесе Н. Н. Минһаҗев